# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2021 елның 18 августы № 46

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 ноябрендәге 185 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2020 елның 25 маендаге 198 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Өтәшкә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 ноябрендәге 185 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (2020 елның 25 маендаге 198 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.7.1 пунктын киләсе эчтәлек белән тулыландырырга:

1.7.1. Гражданнар җыены торак пункт территориясе өлешендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелергә мөмкин.

Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең бер өлеше чикләре, җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләне хәл иткәндә, торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең гомуми мәнфәгатьләре критериеннән чыгып, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә.

1.2. 3.5 пунктта «торак пунктта яшәүчеләр» сүзләреннән соң «(яисә аның территориясенең бер өлеше)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а (мәдәният йорты бинасы).

**Өтәшкә авыл**
**җирлеге башлыгы, Совет рәисе: А.А. Клопов**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1620001214
ОГРН 1021606753486